РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**17.07.2024** Кукмара ш. **№ 408**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында дүртенче һәм аннан соңгы бала туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләү турында

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында балалар туу буенча чара буларак гаиләләрне кызыксындыру максатларында **карар бирәм:**

1. Дүртенче бала туу уңаеннан – 50 000 (илле мең) сум, бишенче бала туу һәм аннан соңгы балалар туу уңаеннан 100 000 (йөз мең) сум күләмендә бер мәртәбә бирелә торган түләү билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында дүртенче һәм аннан соңгы балалар туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләү тәртибе турында кушымта итеп бирелә торган нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

3. Дүртенче һәм аннан соңгы бала туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 17 июлендәге 408 номерлы карарына 1 нче кушымта

Дүртенче яисә аннан соңгы бала туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү тәртибе турында НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә дүртенче яисә аннан соңгы бала туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба шулай ук – бер мәртәбә бирелә торган түләү).
2. Бер мәртәбә бирелә торган түләү суммасы дүртенче бала туу уңаеннан – 50 000 (илле мең) сум, бишенче бала туу һәм аннан соңгы балалар туу уңаеннан – 100 000 (йөз мең) сум күләмендә (НДФЛ ны исәпкә алмыйча).
3. Бер мәртәбә бирелә торган түләү 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр дүртенче яки аннан соңгы бала тапкан хатынга яки шул баланың әтисенә тапшырыла.
4. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен бер үк вакытта ике шарт булу мәҗбүри шарт булып тора:
    1) 2024 елның 1 гыйнварына һәм бер мәртәбә бирелә торган түләү турында гариза биргән көнгә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү;
    2) Ата-аналарның икесенең дә төп эш урыны буенча хезмәт эшчәнлеген Кукмара муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруы.

   Бала үле туган очракта түләү бирелми.

   Хатын-кыз вафат булган, ул ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән (ата-ана хокуклары чикләнгән) очракта, бер мәртәбә бирелә торган түләү баланың атасына (опекунына) бирелә.
5. Балалары тулысынча дәүләт тәэминатында булган гражданнарга, шулай ук ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган түләү билгеләнми.
6. Бер мәртәбә бирелә торган түләү Кукмара муниципаль районы бюджетыннан бирелә.

## II. Бала туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләүне билгеләү һәм түләү тәртибе

7. Бер мәртәбә бирелә торган түләүне билгеләү өчен, әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән гражданнар яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар (алга таба –гариза бирүчеләр) Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

- бер мәртәбә бирелә торган түләүне билгеләү турында гариза;
- паспорт күчермәсе (барлык битләре);
- балаларның туу турында таныклыкларының күчермәләре;
- ананың үлеме турында таныклыгының күчермәсе – үлем турында акт теркәлгән очракта;
- баланың ата-анасының икесенең дә эш урыныннан белешмәләр;

- бер мәртәбә бирелә торган түләүне күчерү өчен банк реквизитлары;
- вәкаләтле зат өчен ышанычнамә күчермәсе.

Документларның күчермәләре төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре нотариус тарафыннан танықланырга тиеш.

8. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә аларны Бер мәртәбә бирелә торган түләү мәсьәләләрен карау буенча комиссия (алга таба – Комиссия) каравына чыгара.

   Комиссия бер мәртәбә бирелә торган түләүне билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысул (смс-хәбәр, электрон почта) белән гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

   Бер мәртәбә бирелә торган түләүне билгеләү яисә аны билгеләүдән баш тарту турындагы карар язма рәвештә рәсмиләштерелә.

   Бер мәртәбә бирелә торган түләү турындагы карар гариза бирүчегә тантаналы шартларда тапшырыла торган Сертификат белән раслана.

   Комиссия карары, мөрәҗәгать итүченең исәп-хисап счетына бер мәртәбә түләнә торган түләүне күчерү өчен, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә җибәрелә.

9. Бала туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләүне билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып,булган белешмәләр һәм документлар җыелмасы нигезендә ачыкланган аны алу хокукының булмавы тора.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

10. Гариза бирүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар булган документларның чынлыгы өчен җаваплы.

11. Комиссия гариза бирүчеләр тапшырган белешмәләрне үзенә тапшырылган вәкаләтләр чикләрендә өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

12. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты бер мәртәбә бирелә торган түләүне алучыларның шәхси эшләрен формалаштыра һәм саклый.

13. Бер мәртәбә бирелә торган түләү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2024 елның 17 июлендәге 408 номерлы карарына 2 нче кушымта

Дүртенче һәм аннан соңгы бала туу уңаеннан бер мәртәбә бирелә торган түләү бирү турындагы мәсьәләләрне карау буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Гарифуллин А.Х. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Әхмәтшина А.М. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Латыйпова З.Т | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |
| Комиссиия әгъзалары | |
| Гаянова Р.Н. | Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Әхмәдуллин Р.Н. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Әхмәтшина А.М. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Минһаҗева Р.З. | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе, комиссия секретаре; |
| Сәмигуллин И.К. | Кукмара муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Мусина Р.Р. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Иванов В.К. | «Татарстан Республикасы ветераннар (пенсионерлар) оешмасының Республика Советы» белән хезмәттәшлек буенча консультант. |